**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 26 апрель № 251

г. Казань

Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\251.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 26 апрель, 251 нче
карары белән расланды

Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү
ТӘРТИБЕ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибе (алга таба – Тәртип) төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килешү процедурасын (алга таба – килешү) билгели.

2. Килешүне Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) гамәлгә ашыра.

3. Килешүнең гамәле эшчәнлекләрен йөртүче белән берлектә гамәлгә ашыручы затларга, шул исәптән хезмәттәшлек, бергә эшчәнлек турында шартнамә нигезендә, шулай ук гамәлгә куючыларының берсе йөртүче булган юридик затларга таралмый. Килешү заказны башка йөртүче башкаруны күздә тотмый.

4. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган «йөртүче» төшенчәсе «Устав Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өстендәге электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закондагы мәгънәдә кулланыла.

## II. Заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне килешү турында гариза бирү

5. Әлеге Тәртипкә кушымтага ярашлы форма буенча төзелгән, юридик затның даими гамәлдә булган башкарма органы җитәкчесе яки әлеге юридик зат исеменнән эш итәргә хокуклы бүтән зат яки бу заказ буенча йөртүче булган шәхси эшмәкәр имза куйган Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килешү турында гариза (алга таба – гариза) Министрлыкка турыдан-туры тапшырыла яки тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта юлламасында җибәрелә (гариза бирүче сайлавы белән).

6. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

гариза бирүченең яки гариза бирүче вәкиленең паспорты күчермәсе;

гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;

билгеле бер заказ буенча заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртергә билгеләнгән һәр транспорт чарасын теркәү турында таныклык күчермәсе;

һәр транспорт чарасын куллану һәм (яки) аның белән эш итү хокукын раслый торган документ (аренда шартнамәсе, лизинг шартнамәсе) күчермәсе;

транспорт хезмәте күрсәтүгә заказның булуын раслый тораган йөртү өчен яллау шартнамәсе яки заказ-наряд күчермәсе;

билгеле бер заказ буенча заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртергә билгеләнгән транспорт чаралары турында мәгълүматларны үз эченә алган транспорт инфраструктурасы объектлары һәм транспорт чараларының категорияләргә бүленгән реестрыннан өземтә;

транспорт чарасы техник тикшерү үткәнне раслый торган диагностика картасы күчермәсе;

Җаваплылыкны иминләштерүчеләр дөньякүләм берлегенең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелгән йөртүченең пассажирларның гомеренә, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян китергән өчен граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе күчермәсе;

картографик нигездә пассажирларны утырту һәм (яки) төшерү урыннары схемасы, адресы һәм координаталары (үрнәк буенча: 55°49′48″N (55.829878) киңлектә 49°6′17″E (49.104829 озынлыкта).

Әлеге документлар юридик затның даими гамәлдә булган башкарма органы җитәкчесе, яки бу юридик зат исеменнән эш итәргә хокуклы бүтән юридик зат, яки шәхси эшмәкәр, яки юридик затның яисә шәхси эшмәкәрнең вәкиле һәр битенә имза куйган күчермәләр рәвешендә, теркәлгән документлар исемлеге белән тапшырыла.

7. Гариза йөртү гамәлгә ашырылачак көнгә кадәр кимендә җиде эш көне алдан тапшырыла.

8. Гаризаны теркәү ул Министрлыкка кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән бер көн эчендә башкарыла.

9. Гаризаны теркәлгән көннән соң бер эш көне эчендә министрлык аны һәм аңарга теркәлгән мәгълүматларны, документларны карап тикшерә һәм аны карап тикшерүгә алу яки карап тикшерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Карап тикшерүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

гаризаны билгеләнгән тәртиптә тапшырмау;

тулы күләмдә тутырылмаган гариза тапшыру;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тулы исемлектә тапшырмау.

11. Гаризаны карап тикшерүдән баш тарту турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Министрлык баш тарту хакында мәгълүматны Министрлык формалаштыра һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү турында гаризалар реестрына (алга таба – реестр) урнаштыру юлы белән гариза бирүчегә хәбәр итә.

12. Гаризаны карап тикшерү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә Министрлык тапшырылган белешмәләрнең

дөреслеген тикшерә һәм заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү турында гариза керүе хакында хәбәрнамәне (алга таба – хәбәрнамә) Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә җибәрә.

13. Хәбәрнамә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә җибәрелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Министрлык заказ белән төбәкара пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү турында яки килештерүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

14. Баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

тапшырылган белешмәләрнең дөрес булмавы;

пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарының юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә һәм юл хәрәкәте кагыйдәләренә туры килмәве;

12 пунктта күрсәтелгән вакытта Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсеннән гариза бирелгән пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарында чикләүләр булу турында мәгълүмат керү;

гариза бирүченең тиешле юридик зат яки шәхси эшмәкәр статусы булмау;

транспорт инфраструктурасының категорияле объектлары һәм транспорт чаралары реестрында транспорт чарасы турында мәгълүмат булмау.

15. Гаризаны карап тикшерүдән яки пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерүдән баш тартылган очракта гариза бирүче, баш тартуның сәбәбе булган кимчелекләрне бетереп, кабат гариза бирә ала.

16. Гаризада күрсәтелгән мәгълүматларга тиешле статус биреп, аларны реестрга кертү килештерү яки килештерүдән баш тарту нәтиҗәсе булып тора.

17. Килештерү турында, килештерүдән баш тарту хакында мәгълүматлар Министрлыкның тиешле карары кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә реестрга кертелә.

18. Килештергәннән соң гариза теркәлгән документлар үзгәргән очракта гариза бирүче аларның таныкланган күчермәләрен тиешле документлар үзгәргән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә Министрлыкка тапшырырга тиеш.

19. Министрлык түбәндәге очракларда килештерүне кире ала:

тиешле документлар үзгәргән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә әлеге Тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаганда;

утырту һәм төшерү урыннарын килештерүне алу өчен кирәкле дөрес булмаган мәгълүматларны һәм документларны тапшыру факты билгеле булганда;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсеннән утырту һәм төшерү урыннары килештерелгән заказны башкарганда йөртүче гаебе белән юл-транспорт һәлакәте килеп чыгу турында белешмәләр килгәндә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсеннән пассажирларны утырту һәм төшерүнең килештерелгән урыннарын алга таба файдалану мөмкин булмау турында

мәгълүматлар кергәндә.

20. Килештерүне кире алу әлеге Тәртипнең 19 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең берсе билгеле булган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Министрлык тарафыннан башкарыла.

21. Килештерүне кире алу турында белешмәләр Министрлык тиешле карарны кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә реестрга кертелә.

22. Реестрдагы статусы үзгәргән көннән соң килештерү кире алынган дип санала.

Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына

____________________________________

(йөртүче исеме)

____________________________________

(йөртүченең ИНН)

____________________________________

(йөртүченең ОГРН)

**Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан утырту һәм төшерү урыннарын килештерү турында**
**гариза**

Сездән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан «__________ – ___________» заказ белән төбәкара маршруты буенча пассажирлар һәм багажны утырту һәм төшерү урыннарын килештерүне сорыйм.

Үз имзасы белән гариза бирүче түбәндәгеләрне раслый:

әлеге гариза теркәлгән документлар һәм мәгълүматларның дөреслеген;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә шәхси мәгълүматлардан файдалануга ризалык;

пассажирлар һәм багаж йөртү өлешендә законнарны саклау.

Кушымта: 1) утырту һәм төшерү урыннары исемлеге __ биттә __ данәдә;

2) Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында җирлекләр территорияләрендә пассажирларны утырту һәм төшерү урыннарын килештерү тәртибенең 6 п. нигезендә мәгълүматлар __ биттә __ данәдә;

Вазыйфа ______________ / ________________

(имза) ( Ф.И.Ат.и.)

Төбәкара заказ белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан утырту һәм төшерү урыннарын килештерү турында гаризага кушымта

Форма

**Пассажирлар һәм багаж утырту һәм төшерү урыннары исемлеге**

Заказ маршруты «_____________ – ______________»

Көне «___»__________ 20___ел

| Т/с | Утырту/төшерү урыннары (адрес) | Көне | Вакыт |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| … | | | |

Вазыйфа _____________ / _______________
(имза) (Ф.И.Ат.и.)

_______________________________________